Әлмәт муниципаль районы Башлыгы
карары

03 июнь 2020 ел. № 29

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2019 елның 9 августындагы 6172 и номерлы Әлмәт муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча комиссия бәяләмәсе нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Иске Михайловка авыл җирлеге, Иске Михайловка авылы, Автомобиль урамы адресы буенча 3998 кв.м мәйданлы җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча №3.7 кодлы «культ объектлары»- «дини файдалану» төзелә торган җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Үткәрү вакыты - әлеге карар басылып чыккан көннән алып кимендә бер айдан да ким булмаган вакытка.

3. Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Иске Михайловка авыл җирлеге, Иске Михайловка авылы, Мәктәп ур., 43 й. адрес буенча 2020 елның 11 июнендә 11:00 сәгатьтә уздырырга:

4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт, адресы буенча урнашкан Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 11 июненә кадәр башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

5. Иске Михайловка авыл җирлеге башкарма комитетына (Абдуллин И.М.) гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләүне һәм уздыруны тәкъдим итәргә.

6. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы Т.Д. Нагуманов